**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 117**

Мөслим авылы «30» август 2022 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иҗтимагый советын төзү турында» Мөслим муниципаль районы Советының 2022 елның 31 маендагы 100 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының киңәшмә беркетмәсен үтәү йөзеннән муниципаль берәмлекләр башлыкларының 24.05.2022 №313 иҗтимагый яшьләр ярдәмчеләре статусы турында үрнәк нигезләмәне эшләү мәсьәләсе буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль район Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы халык язучысы, Тукай премиясе лауреаты Садриев Фоат Миңнеәхмәт улын Мөслим муниципаль районының Иҗтимагый советы составыннан чыгарырга.
2. Мөслим муниципаль районы Иҗтимагый советы составына Казан шәһәре Идел буе районының муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе 68 нче номерлы мәктәбенең физик культура укытучысы Ногманов Булат Фаил улын, коррупцияне профилактикалау буенча Мөслим муниципаль районы Башлыгының иҗтимагый яшьләр ярдәмчесе сыйфатында кертергә.
3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иҗтимагый Советы составын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М.Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р. Хуҗин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль
районының 2022 елның
«30» августындагы 117
номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының Иҗтимагый советы составы

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1. | Солтанов Рушат Җәүдәт улы | Мөслим районында Татарстан халыклары Ассамблеясе вәкиллеге җитәкчесе, совет рәисе (килешү буенча) |
| 2. | Кирамова Фәридә Хәмит кызы | Пенсионер, хезмәт ветераны, совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Заһидуллина Эльвира Фәдүт кызы | «Мизгел» яшьләр үзәге» МБУ өстәмә белем бирү педагогы, совет секретаре (килешү буенча) |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 4. | Низамов Илгиз Хафиз улы | Мөслим муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе (килешү буенча) |
| 5. | Афзалова Римма Рәшит кызы | «Татмедиа» АҖ «Мөслим мәгълүмати-редакция үзәге» филиалы директоры (килешү буенча) |
| 6. | Гәрәева Эльвира Илфат кызы | «З.Басыйрова исемендәге район мәдәният йорты» МБУ сәнгать җитәкчесе, Мөслим муниципаль районында «Ак калфак» иҗтимагый берләшмәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7. | Әхмәтҗанов Мөҗәһит Заһит улы | Балалар язучысы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы (килешү буенча) |
| 8. | Изибаева Әнисә Альберт кызы | «Татарстан Республикасы Мари милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының җирле бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 9. | Светлякова Галина Виктор кызы | «Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының җирле бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 10. | Госманов Данил Дамир улы | Мөслим муниципаль районының локаль хәрби хәрәкәтләр ветераннарының җирле иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| 11. | Мортазин Гүзәл Гизәр улы | Пенсионер, хезмәт ветераны (килешү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 12. | Романова Галина Степан кызы | Мөслим муниципаль районында «Керәшен коммерциячел булмаган оешмалар» РОО җирле бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 13. | Сөнгатуллин Илгиз Шәүкәт улы | Мөслим районы имам-мөхтәсибе, «Җәмигъ» мәчете имам-хатыйбы (килешү буенча) |
| 14. | Бәдретдинова Нәзилә Наил кызы | «Мөслим туган якны өйрәнү музее» МБУК директоры (килешү буенча) |
| 15. | Ногманов Булат Фаил улы | Казан шәһәре Идел буе районының муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе  68нче номерлы мәктәбенең физик культура укытучысы (килешү буенча) |